ГОМЕР АГЫШЫ - ЙӨРӘК САГЫШЫ



Муниципаль мәдәни казна учреждениесе
Үзәкләштерелгән Малмыж китапханә системасы
Г. Тукай исемендәге Иске Йөрек авыл китапханәсе –
татар мәдәни үзәге

Гомер агышы – йөрәк сагышы

Иске Йөрек
2017

Төзүчесе
Е. Н. Касимова

Компьютерда җыючы
Е. Н. Касимова

Чыгарылыш өчен җаваплылык
М. Т. Хасанова

12 +

Гомер агышы – йөрәк сагышы: истәлекләр / төз. Е. Н. Касимова, җаваплы ред. М. Т. Хасанова. – Малмыж : ММКУ Малмыж ҮКС, Г. Тукай исемендәге Иске Йөрек КФ, 2018.- 28 б.

Җыентыкка Хакимова Тәскирә апа сөйләгәннәреннән сугыш елларында туган, авыр тормыш юлы узган әти-әнисе турында истәлекләр тупланды.

Водовороты жизни : воспоминания / сост. Е. Н. Касимова, ред. М. Т. Хасанова. – Малмыж : МКУК Малмыжская ЦБС, Староирюкская СБФ – центр татарской культуры им. Г. Тукая, 2018. – 28 с. – (В Победе их немалая заслуга).

Выпуск издания реализован в рамках проекта «Живая легенда». Финансовая поддержка проекта осуществлена благотворительным фондом «Хорошие истории» в рамках программы «Активное поколение».

©ММКУ Малмыж ҮКС, 2018

Т. 15 экз

Һәр гаиләдә – бер үк язмыш

Соңгы елларда сугышта ирен,улын югалткан хатын-кызлар да азаеп бара, фронтовиклар үзләре инде бетеп килә. Утлар- сулар кичкән бу кешеләрнең безнең арада сирәгәя баруы кызганыч. Ватан язмышы өчен җанын бирергә торуның бер үрнәге булып яшиләр бит алар. Без аларның тормыш һәм сугышчан юлларын өйрәнеп, халкыбызның менә шул батырлык һәм фидакарьлекләрен киләчәк буыннарга да сөйләп калдырырга бурычлы.

Сугыштан соң да алар, сугыш һәм тыл каһарманнары, көнне төнгә, төнне көнгә ялгап, ил язмышына кушылып, хезмәткә җигелгән. Хәзер алар гаиләдә олы ихтирамлы кешеләр, балаларының таянычы, якыннарының юанычы. Алар әле дә олы йөрәкле, нык бәдәнле,саф күңелле әүлия затлар, сугыш чоры кешеләре!

Һәр яз ничектер үзгә. Күк тә биегрәк, зәңгәррәк. Җылы җилләр үзләренең назлы канатлары белән барлык тереклек ияләрен иркәләп исәләр. Дөньяда яшел яфрак һәм сагыш исе. Бу сагыш – җаннарны яралаган авыр сугыш елларыннан килә. Бу яралы җаннарның шаһитлары – авылыбызның тынгы белмәс, тормышка, хезмәткә гашыйк кешеләр. Алар йөрәкләре үксеп – үксеп елаганда да, кайгыга түзә алмый җаннары бәргәләнгәндә дә, якты кояшлы дөньяга мәхәббәтләрен югалтмыйча, кешеләргә карата миһерлек саклап матур гомер гомерләүчеләр.

Бу җыентыкка кергән истәлекләрне безгә җиткерүчеләр, әби – бабалары, эти – әниләре, туганнары, үзләренең язмышларына битараф булмаган олы җанлы кешеләр.

Агар сулар...

(Хакимова Таскирә сөйләгәннәрдән язып алынды)

Ага да ага сулар. Туктау да юк, тыну да юк. Вакыты белән шаулап – ургып, вакыты белән тын гына ага. Кеше гомере дә шулай...

Агыла да, кагыла да...

Тормыш дәрьясында гизәр өчен кешегә бик чыдам канатлар кирәк. Ул канатлар пар булганда, бер – берсенә терәк булырлык булганда гына , җил давылларга бирешмичә гомер юлын үтәрлек чыдам була. Мин әтием белән әниемне бик тырыш, сабыр кешеләр итеп беләм. Әтием Сәләхетдин улы Мөдәррис һәм әнием Нәбиулла кызы Гөлҗиһанның үткән гомер юлларын – гүзәл язларга, чәчәкле җәйләргә, мул – юмарт көзләргә тиңлисем килә. Ярты гасырдан артык узган тормыш юлында күз ачкысыз бураннар да, әче җилләр дә булмый калмагандыр, тик алар бирешә торганнардан булмаган. Тормышка булган үҗәтлекләре корыч белән чагыштырырлык, ә әниемнең сабырлыгы берничә кешегә бүлеп бирергә җитәрлек булган.

Әтием дә, әнием дә 1930 елның март аенда Иске Йөрек авылында туганнар. Аларның балачак, яшьлек еллары да, картлык көннәре дә берлектә, туган авылларында уза.

Әниемнең әтисе – Нәбиулла, ул 1896 елгы була, әтисе Әхмәткәрим белән бергә эшләп көн күрә. Әхмәткәрим бабай ул чорда, тирә – якка дан тоткан яргыччы (тегермәнче) була. Алар ат белән тегермән тартканнар. Хезмәтләре ошаганга да, кешегә булган яхшы мөгаләмәләре дә авыл кешеләрен дә, чит авыл кешеләрен

дә үзләренә тартып торган. Хезмәтенә күрә хөрмәте дигәндәй, ул вакыт өчен алар бераз мал туплап, хәлле кешеләрдән саналган. Тормышлары да җай гына барып, Нәбиулла бабам үзенең язмышын Шиһабетдин кызы Гыйлембану белән бәйли. Әбиемнәр алты бала булып үсәләр: Ахматхан, Ахмадулла, Гыйматетдин, Галимҗан, Сәгыйдәбану. Бабай белән җиде бала тәрбияләп үстергәннәр: Гөлҗәүһәр, Аухатша, Нурҗиһан, Гөлҗиһан, Гөлниса, Нурбиса, Һаҗәр.

Ләкин дөньяда кеше үз тормышын үз ихтияры буенча гына көйләп бара алмый. Тарих тәгәрмәче дигән әйбер кайбер чорларда аяусыз бик явыз булган. Ул үзенең тешләре белән күп нәрсәне таптаган, сыткан, җимергән, юк итәргә дә җөрьятләгән. Шундый чорның берсе – колхозлашу вакыты. Үз көчләре, фидакарь хезмәтләре белән табылып, тупланган малны тулаем алып чыгып киткәнәр. Берничә сыер, ат, хәтта тагаракларын да кубарып алганнар. Башка әйберләрнең исәбен дә алып тормадылар, дип искә ала торган булган әбием. Хәләл хезмәт җимешен тартып алучыларга бер дә риза булмаганнар, тик совет властенә каршы килеп булмаган, чөнки хөкүмәтебезнең сәяси карашы бу. Тырышып тапкан малларны талап җыеп, кемнәрнедер сөргенгә җибәреп колхозлар төзегән илебез. Кеше күз яше, гомере белән җыелган ул байлыклар бүгенге көндә кем кулында икән? Бу сорауга җавапны кайсы түрәдән сорасы?

Нәбиулла бабам кыска гомерле булган, 1949 елда вафат була. Гыйлембану әбиемне яхшы хәтерлим.

Гыйлембану әби (1980 ел)

Әбиебез безнең белән тормаса да, безне якын итеп, гел килеп йөрде. Әтиебез дә әбине хөрмәт итә, олылый иде. Әбиебез килеп керсә, әтинең йөзләре яктырып, нурланып китә, йортка ямь өстәлә иде. Әбиебез безгә нинди дә булса тәм – том, конфет ише әйберләр алып килә, аны баш түбәбезне сыйпап – сыйпап кулыбызга тоттыра иде. Моның да үз сәбәбе булган икән, гомер узу белән генә төшендем. Бала – чаганың энергиясе ташып тора, баш түбәсенә кул куйгач ул энергия олы кешегә дә күчә икән, менә ни өчен элеккеге әбиләр балаларның башын сыйпаучан булган, җор күңеллелек тә аларга шулардан иңгәндер.

Әбиебез бик чиста, матур итеп киенә иде. Без аны бик яратып, сагынып көтеп ала идек. Әбиебез безне гел

әниебезгә булышып, ярдәмләшеп яшәргә өйрәтте. Әниегезнең эше бик күп, ул бөтен эшкә дә үзе генә җитешә алмый дип, эшләрнең тәртибен төшендерде. Иң элек капка төбе белән ишек алдыгызны чиста тотыгыз. Һәр көн иртән баскыч төпләрегезне юып куегыз, аннан су эчә торган чүмечегез белән су савыты ялтырап торсын. Бу эшләрнең мәгънәсен дә төшендереп бирә. Кеше иң элек сезнең капка катына аяк баса, ишек алдына үтүче дә булыр. Су сорап кергән юлчылар да булуы мөмкин, су сузган чүмечен чиста булмаса, ояты сезгә булыр. Ул вакытта табалар, кастрюльләр корым,төтен белән карала иде. Әбиебез шуларны инештә ком, көл белән агартырга өйрәтте. Әбиебез аш – суга да бик оста булды, безгә хуҗалык буенча киңәш биргән арада, тәмле ризыклар да пешереп өстәлгә куя иде. Әбиебезгә, урыны оҗмахта булсын, олы рәхмәт, ул бездә хезмәткә мәхәббәт тәрбияләп үстерде.

Әтиемнең әтисе Сәләхетдин, Низаметдин бабайның җиде баланың берсе була.

Сәләхетдин бабай (1969 ел)

Алар: Сәләхетдин, Шәйхетдин, Гайфетдин, Зәйнетдин, Зәйнулла, Хәлиулла һәм Нәгыймә.Сәләхетдин бабам беренче Бөтендөнья сугышында катнашкан. Сугыштан ул бер аягы яраланып, пуля аягының тездән шактый югары өлешеннән кереп табан астыннан чыгып, кайткан. Гел таякка таянып йөрде, шулай булса да, йорттагы вак – төяк эшләрне бик теләп башкара иде. Минем хәтергә ул уен – көлке яратучы җор күңелле, чиста, эшчән бабай булып кереп калган. Ә, менә Миңсылу - Фәйзрахман кызы - әбием, бабамның тормыш иптәше, уен – көлке ярата торган кеше түгел иде.

Миңсылу әби (1975 ел)

Бабай аны Кариледән алып кайткан. Әби бик уңган, булган кеше иде, кулыннан килмәгән эше юк. Авыл халкына колмактан чүпрә ясый иде, безгә күлмәкләр тегеп киертте. Ул үзе кисүче, үзе тегүче булды. Чисталыкны,

пөхтәлекне бик яратты. Ашарга пешерергә бик булдыра иде. Шул хәтердә калган, ул чорларда ашаганда һәр кешегә үз өлешен бүлеп бирү иде, әни өйдә булмаса әби анының өлешен алып куя да, анысына тимәгез дип кисәтергә дә онытмый. Әбием үзенә күрә гадел кеше иде, мин аны чын каенана итеп күзаллыйм. Әтиемнең алты туганы булган: Зәйтүнә, Рашида, Камил, Тәзкирә, Мөслимә, Габделхай. Бүгенге көндә Мөслимә апа гына исән – сау, туган авылында гомер итә.

Тарих тәгәрмәче аяусыз әйләнеп иң зур афәтне – 1941 елгы Бөек Ватан сугышын алып килә. Сугыш башлангандә этием белән әниемә унбер яшь була. Авылдагы барлык ир – атларны, үсеп буйга җиткән егетләрне көн дә фронтка җибәреп тордылар. Колхозның иң яхшы, таза атлары сугышка алынды. Тазарак дип исәпләнгән, эшкә яраклы олырак ир – атларны хәрби заводларга, хезмәт армияләренә алдылар. Хатын – кызларны окоп казырга, яшьүсмер малайларны ФЗӨгә җибәрделәр. Авылда карт – карчыклар, яшь балалы аналар, яшь кызлар һәм малайлар гына калган. Шушы карточкада алар – 1930, 1931 елгы балалар. Алар җилкәсенә дә бик күп авырлыклар, сынаулар төшкән. Түбәндәге карточкада алар.

Колхоз эшен, авыл тормышын, үз хуҗалыгынны алып бару – бар да алар җилкәсенә төшкән. Шушы авырлыклар өстенә, канлы күз яшьләре түктереп, авылга бер – бер артлы кара кәгазьләр килә. Гарипләнеп кайткан сугышчылар да күренә башлый авылда. Шундыйлар арасында әниемнең абыйсы – Набиуллин Аухатша да була. Ул 1944 елның ноябрь аенда демобилизацияләнеп кайта. Аны 1943 елны, 18 яше тулу белән фронтка алган булалар. Витебск шәһәре янында яралана. Кулы белән аягы җәрәхәтләнә, аягы төзәлә, ләкин кулы әкренләп кибә. Авылга кайтып кергәндә, халык каршы алырга урамга чыккан була. Аухатша абыйларның ишек аллары, капка турлары, урам кеше белән тулган булган. Аларныңкайсы елаган, кайсы җырлаган, гармун тарткан, кайсы үз якыннары турында йөрәк өзгеч сораулар биргән. Һәр сугышчының фронттан кайтуы авыл өчен зур вакыйга

булган. Абыебыз сугышта күрсәткән батырлыклары өчен: 3 дәрәҗә “Дан” ордены, “Батырлык” һәм “Сугышчан батырлык” өчен медальләр һәм “Кызыл йолдыз” ордены белән бүләкләнә.

Авылда тормыш, эш шартлары, көн күрү дәрәҗәсе торган саен авырая, кискенләшә. Һәрнәрсә граммлап кына бирелә. Салкыннарда кырдан чергән бәрәңге җыеп ашаганнар. Яшеллек күренә башлау белән кычыткан ашы, алабута ипиләре ашап тамак тукландырганнар. Ачтан шешенеп үлүчеләр бик күп булган. Кеше генә түгел, хәтта хайваннар да ачтан үлгән. Болай ук авыр да булмас иде бәлкем, әгәр дә бар булдырган, җиткергән әйбер фронтка җибәрелмәсә... Бар кеше җиңү өмет иткән, үз хезмәте, көче белән аны якынайткан һәм ул килгән, меңнәрчә, миллионлаган корбаннар белән килгән. 1945 елның 9 май көнендә безнең илгә җиңү сөенече ингән. Бу сөенечле хәбәрне Мәгьсүмә апа Нәбиуллина телефоннан кабул итеп, авыл халкына җиткерә. Мәгьсүмә апа ул вакытта авыл советы секретаре хезмәтен үтәгән.

Сугыштан соңгы еллар да бик авыр була: күп кешенең каралты – курасы тузган, җимерелгән, басуларны чүп үләне баскан, җирне эшкәртергә атлар да, кораллар да юк. Авылда ачлык, хәерчелек, әтисез калган ятимнәр, тол калган хатыннар, уллары сугыш кырларында калган ялгыз карт – карчыклар...

Сугыштан соңгы авыр 50нче еллар. Колхозлар таралып беткән дәрәҗәдә һәм шушындый авыр 1950 елны “Чулпан” колхозының рәисе итеп Камалов Әхмәтриза абыйны куйганнар. Әхмәтриза абый сугышның башыннан ахырына кадәр яу кырында уздырган кеше. Ул Берлинга барып җитеп, Рейстах стенасына үзенең имзасын салып

калдырган батыр сугышчыларның берсе булган. Колхоз рәисе булып эшли башлагач, әнием Гөлҗиһанны склад мөдире итеп билгеләгән. Әниемгә бу эшне алып бару җиңел булмый, чөнки аяк чалучылар үзләренең мәкерле ниятләрен тормышка ашыру өчен бер нәрсә алдында да туктап калмаганар. Әнием өстеннән гел шикаять язып, тикшерү чакыртып торганнар. Күрәсең бу кешеләр әнине гаепләп эшеннән алдырып, үз кешеләрен мөдирлек эшенә урнаштырыргә теләгәннәрдер, тик аларның мәкерле ниятләре тормышка аша алмаган. Әнием һәр тикшерүчене матур итеп елмаеп каршы алган, тикшерү эшләре уңай нәтиҗәләр белән төгәлләнгән. Ул үтә гаделлек белән эшләгәч, сыерын саттырып җитмәүчелекне түләттерәбез дигән сүзләргә исе китмичә 1959 елга кадәр мөдир вазыйфасын башкарган. Әхмәтриза абыйны әни гел яхшылык белән искә ала торган иде. Ул аны искиткеч яхшы, киң күңелле, миһербанлы дип сөйләде. Рәис булып торган заманда колхоз эшен генә кайгыртмыйча, авыл халкы өчен дә бик күп файдалы эшләр башкарган. Өйсезләрне өйле итте, ачларны тук итте, юкларны бөтенәйтте һәм 1959 елда кылган яхшылыклары өчен, авылдан ук чыгып китәргә мәҗбүр булган. Һәр чорның явыз ниятле кешеләре була, болар да үз зшләрен җиренә җиткереп башкарганнар, Әхмәтриза абыйны эшеннән алдырганнар. Әнием бу кешеләрне беләбез, дип әйтә торган иде, тик бу язмада аларны атау, туганнарына, якыннарына авырлык китерү булыр. Әхмәтриза абый үзе эштән киткәндә, әнине дә мөдир вазыйфасыннан азат итә, чөнки аңар эшләргә мөмкинчелек бирмәсләрен яхшы аңлап, гадел хезмәте өчен рәхмәт белдерә. Искиткеч яхшы кешене дә безнең авыл халкы үз итмәде. Әхмәтриза абый

авылның байлыгы – аның үз халкы булганын аңлап эш итте, дип, гел офтанды әнием.

Әнием мәхәббәтен дә үз авылында очрата. Алар әти белән ызбачта, кичке уенда танышалар.

Әнием (1953 ел 19 июль)

Әти бик оста тальян гармунда уйнаучы булган. Тормыш никадәр авыр булса да, яшьләр шау – гөр килеп күңел ачканнар, тормышка сөенә белгәннәр. Әти белән әни дә матур гына итеп очрашып йөри башлыйлар һәм 1950 елның беренче июлендә әтине армия сафларына алалар. Әни әтине көтәргә сүз биреп, армиягә озата. Армиягә китәр алдыннан әтием сөйгән яры белән дә,

яшьтәшләре белән дә карточкаларга төшеп, түбәндәге сүзләрне әйтеп җырлаганнар:

Бу дөньяда бер кешенең дә
Калмас тере гәүдәсе,
Калса калыр истәлеккә
Гәүдәсенең шәүләсе.

1950 елда төшерелгән бу карточканың беренче рәтендә: Гайнуллин Салихҗан, Сәләхиев Мөдәррис, Назипов Шарифулла, Латыпов Гарәфетдин, икенче рәтендә: Дәүләтшин Нурислам, Ахметшин Нил, Каримов Гаяз, Закиров Гәрәй, өченче рәтендә: Мубараков Наил, Әхмәткәрим, Гафиуллин Мөнир,Закиров Г.

Бу карточкада әти белән әни, Зәйтүнә апабыз, Васил, Коттүс, Җәүһәрия.

Әтием дүрт ел да дүрт ай, 1950 – 1954 еллар, хәрби хезмәттә була. Ул Германиядә, хәрби аэродромда борт – механик булып, өлкән сержант дәрәҗәсенә ия булып кайта. Әнием белән хатлар алышалар, бер – берсенә карточкалар җибәреп торалар.

Привет из Германии
С новым годом!
1954
Bier

Хәрби хезмәттән кайткач, 1955 елны әтиебезКрасная Поляна эшчеләр бистәсендә авыл хуҗалыгы училищесын бишле билгеләренә генә тәмамлый.



АТТЕСТАТ

№ 300

Выдан гр. Саляхиеву Мударису
Сал рождения 1930 года в том, что он
окончил училище механизации сельского хозяйства № 11 в раб. пос. Красная Поляне
(указать местонахождение училища)
и выдержал выпускные квалификационные экзамены
Отлично
(указать оценку)
Решением экзаменационной комиссии от 7/VIII 1955 года гр. Саляхиеву М. С.
присвоена специальность тракториста слесаря
квалификацией
гр. Саляхов М. С.
имеет право работать
На колёсных и гусеничных тракторах и с/х машинах
Председатель экзаменационной комиссии
М. печати
Директор училища Пономарев
Выдан 10. VIII 1955 г.
Город (село) В-Поляна

За время обучения в училище механизации сельского хозяйства с 4.02.1955 года по 7.08.1955 года гр. Саляхов М. С. изучил — нижеперечисленные предметы выполнил — практические работы и получил — следующие оценки:

Наименование предмета	Оценка
Политзанятия	«5» (отл)
Основы агрономии	«5» (отл)
Тракторы	«5» (отл)
С/х машины	«5» (отл)
Организ. тр. раб.	«5» (отл)
Производ. практ.	«5» (отл)
Слесарно раб. дело	«5» (отл)
Государст. экзамен	«5» (отл)

Зам. директора училища по учебно-производственной части Пономарев

Ул үзенең алган һөнәренә ахыргача тугры калды. Иң элек дизель тракторында, аннан соң тәгәрмәчле тракторларда эшләде. Хезмәтен гел намус белән башкарды, пенсиягә дә шул тармактан, “Хезмәт ветераны” исеменә ия булып чыкты. 1966 елның көзендә Хасанов Закирҗан белән зәб сукалаган чордагы карточкасы да бик матур булып сакланган.

Кеше күңелен яулап алган олы хисләр ваемсызлыкка урын калдырмый тамыр җәеп, мәңгегә сакланса иде. Тамырлары таза булып, яшәү көче биреп торсын өчен, гомер агышында кайгыларны уртаклашып, шатлыкларны бүлешеп яшәрдәй пар кирәк. Кош канаты белән, гаилә татулыгы белән көчле.

Гомер агышында бергә – бергә тормыш йөген тарту өчен 1956 елда әтием белән әнием никахлашалар. Әнием түбән оч инеше буенда яшәүче Сәләхетдин бабайлар

йортына килен булып төшә. Ул килен булып төшкәндә инеш буйларының матурлыгына, чисталыгына искитәрлек, хәтта керне дә инеш суында чайкый идек дип сөйли иде әни. Мал – туарга да суны инештән эчерткәннәр. Суда тәңкәләрен ялтыратып йөзеп йөргән балыкларга карап туя алмаслык булган. Без үзебез дә, үсмер вакытта, шул инештән балык тотып, шуның суында ялан аяк уйнап, су коенып үстек. Шул чор кешеләре бу су буйларын бүгенге көндә күрсәләр, ни диярләр иде микән? Бүгенге көн кешеләре әби – бабаларыбызның күп сорауларыннан уңайсызланып, җавапсыз калыр иде, мөгаен.

Без гаиләдә дүрт бала булдык: Тәзкирә, Әлфия, Вагыйз, Фәнис. Әтинең энесе булганлыктан, безне башка чыгардылар. Ул вакытта кече энебез Фәниската, нибары өч – дүрт ай булгандыр. Бүгенгедәй хәтеремдә, җәй көне дизель тракторына чана тагып, булган әйберләрне шуңа төяп, бабабыз йортыннан чыгып киттек. Юлыбыз керосин тавыннан, керосин сата торган, җиргә казылып кергән алачык булганга шулай исемләнгән, менеп китәсе иде. Мин әти янына кабинага кереп утырдым, әни чанада урнашты. Үзем сөенәм, чәнки миңа үзгәреш, яңалык, ә әтинең күзләрендә мөлдерәмә тулы күз яше.Әтием ул вакытта бик каты елады, мин аның ник елаганын аңламадым. Күп еллар узгач кына мин моның сәбәбенә төшендем.

Кечкенә генә мунчада алты кеше тора башладык. Кышның салкыннарында нәни бозауны да алып керә идек әле. Ничек сыйганбыздыр? Дөнья бер урында тормый бит, безнең дә әти белән әни әкренләп йорт җиткерделәр. Йорт җиткерү җиңел эш түгел, әниемнең бер тапкыр бик

ачынып елаганын хәтерлим. Нигә елыйсың дигәч, әтиеннең унөченче хезмәт хакын түләмәгәннәр. Бар бит кешеләр, балалар хакын да уйламыйлар, өй салабыз, дүрт бала, ул акча безгә бик кирәк иде. Мин шуңа өметләнгән идем. Дүрт аяклы ат та сөртенә, без бит кешеләр, кеше нинди дә булса хата ясарга мөмкин, болай җәзаларга кирәкмәс иде. Әйе, әтием салгалады, ләкин эшенә чыкмый калганы булмады. Эшен тә бик яратып эшләде, пөхтә иде, эш урыны гел тәртиптә, эшләгән техникасы гел төзек булды. Хезмәттәшләре ихтирам итте. Әтием нигә болай эшлисең дигәч, йөрәк әрнүенә чыдап булмый, минем хәлләрне үсеп, тормыш итә башлагач аңларсыз әле диде. Еллар узгач аңладым, мәрхүм әтием, гаделсезлектән үзенә шундый юаныч тапкан. Әтиебезнең тормышка ашмаган бер хыялы калды, ул гел очучы – летчик булырга теләгән. Аның бу теләгенә тормышка ашарга насыйп булмаган инде. Пенсиягә чыгуны үләргә документ алу белән бер дип әйтә иде, шулай булды да. 1990 елның 14 мартында пенсиягә чыкты һәм шул ук елның июнь аенда бакыйлыкка күчте. Йөрәк сыкравы белән искә төшерәбез әтине – гел суык тракторда, вакытлы – вакытсыз ашаулар, салкын ризык белән аяк өсте капкалап алулар, иртәнге өчләрдә урман кисәргә чыгып китүләр, ярты төн җиткәч кайтулар, болар барысы да аның тазалыгын какшаткан инде. Ел саен медосмотр узып торсалар да, үпкәсендә кара тап булуын,үзе үлгәч килгән хаттан гына белдек.

Әнием күп еллар ике тармакта: терлекчелектә һәм кырчылыкта бригадир вазыйфасын башкарды.

Әнием (1980 ел)

Әниемнең әше җиңелләрдән булмады. Кешене эшкә кушып, эшләгәнең исәпкә алып хезмәт хакын санарга, ниндидер эшкә кеше тапмаса, үзебезгә дә эшләргә туры килә иде. Бик соңлап фермага барып сыер сауган вакытлар шактый күп була иде. Чөгендер басуында, бүленеп бетмәгән җирләрне, чүп утаулар да күңелдән китми. Ул эш өчен печән бирәләр, печәне булыр дип эшләтә иде әниебез. Әниебез бик тырыш, сакчыл булды. Хәтердә уелып калган кайбер вакыйгалар моның шулай булуын кабат раслый. Түбән очта, бабайлар өендә торганда чыпта сугу бар иде. Төн буе сугалар чыптаны, иртән эшкә барасылары, йокларга вакыты да калмый иде әнинең. Шулай тырышып чыпта суккан акчага ул үзебезгә дип, тегү машинасы алды. Миңсылу әбинең үзенеке бар иде инде ул чакта. Бүленеп башка чыкканда Миңсылу әби шул тегү машинасын бирмәде әнигә. Әнинең сорап

алырга кыюлыгы җитмәде. Мин этигә бу хәлне әйткәч, ул аптырап, сүзсез калды, ә минем уемча кешенең хәләл көч куеп алган малы үзенә булырга тиеш. Менә шулай итеп, кайбер каенаналар җае белән дөньяны кайнаталар. Халык та, тоз шикәр булмас, килен кыз булмас дип, юккагына әйтмәгән. Шушы хәлдән соң Гыйлембану әбием үзенең тегә торган машинасын, көрән чуклы шәлгә төреп, әниемә китереп бирде. Артык авыр булмагандыр инде ул, үзе күтәреп килде һәм Гөлҗиһан кызым, бу тегү машинасын сиңа бирәм, апаларынның, сеңелләреннең үзләренеке бар, синеке генә юк, турыга булса да кирәк – яракларынны тегәрсең. Ике кызынны да тегәргә өйрәтерсең диде. Бу безнең өчен зур вакыйга булып, бер дә күз алдымнан китми.

Әниебез безне эш сөяргә, гадел булырга, кеше танырга өйрәтте, киңәшләрен биреп торды. Беркайчан да чибәр, матур кешегә исегез китмәсен, чөнки матурлык туйда, акыл көн дә кирәк дип әйтә иде. Кешенең асылын белер өчен, аның белән бер пот тоз ашарга кирәк, ә ул кадәр тозны кеше гомере буе ашый, димәк ул кеше белән гомер кичү кирәк булган. Ялагай, юха телле кешеләрдән ары булыгыз, аларның зыяны зур булыр дип әйтә иде. Әниебез сүзләренең мәгънәсенә тормыш дәверендә төшендек. Рәхмәт, әниебезгә, тормыш дәресләре өчен.

Әнием лаеклы ялга, “Хезмәт ветераны” исеменә лаеклы булып чыкты. Ул бу эштән туктагач, аның урынына ике бригадир куелды, машиналар бирелде, әниебезнең җәяү йөргән юлларыннан машина тәгәрмәчләре тәгәрәде...

Әниебез белән этиебез сугыш чоры балалары. Алар үзләренең авыр, әче язмышларына тигән өлешне зур

сабырлык белән кабул иткәннәр. Дәрәҗә, дан, шөһрәт казаныр өчен яшәмәгәннәр, ялганчылар, ялагайлар белән бер юлдан бармаганнар.

Кояшка карап, кояш була алмасалар да,

Тауга карап, тау булмасалар да,

Кешегә карап, кеше була белгәннәр

Үз җаннарының тиңе булып калганнар, - дип, горурланабыз.

Тормыш юлын бергә башлап, ахыргача туры һәм тугры юлдан бару, хөрмәткә, соклануга лаеклы зур эш. Гомер узып олайган дәвердә дә, бер – береннең күзенә туры карап сөйләшерлек, серләшерлек урын калырлык булсын!

Тормыш итү - кыр аша гына үтү түгел, ул – бер – берен өчен җаваплылык хисен тоеп, хөрмәтләп, кирәк булганда җитди карарлар кабул итеп яши белү. Ел фасыллары үзгәреп торган кебек, тормышның да төрле чагы була, шуны аңлап, асылына төшенеп, үзгәртергә кирәк булганын үзгәртеп, төзәтергә кирәген төзәтеп яши белү кирәк. Әйләнә – тирәсен күңеле белән күреп кабул итә алган кеше генә, тормышка уңай үзгәреш кертә ала.

Водовороты жизни : воспоминания / сост. Е. Н. Касимова, ред. М. Т. Хасанова. – Малмыж : МКУК Малмыжская ЦБС, Староирюкская СБФ – центр татарской культуры им. Г. Тукая, 2017. – 28 с. – (В Победе их немалая заслуга).

Выпуск издания реализован в рамках проекта «Живая легенда». Финансовая поддержка проекта осуществлена благотворительным фондом «Хорошие истории» в рамках программы «Активное поколение».

Муниципальное казенное учреждение культуры
Малмыжская централизованная библиотечная система
Староирюкская сельская библиотека – филиал № 29
Центр татарской культуры им. Г. Тукая
Адрес:
612941, Кировская область, Малмыжский район,
село Старый Ирюк, ул. Садовая, дом 2-а;
Дом культуры, 2-й этаж
casimova.lena2015@yandex.ru